ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

13.05.2019 № 738

«2019-2023 елларга Алабуга муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль Законын, «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль Законын, «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2010 елның 21 гыйнварындагы 7-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 31 октябрендәге 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2014 – 2016 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасы һәм Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставына таянып, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «2019-2023 елларга Алабуга муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасын расларга (1 нче кушымта).
2. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2016-2019 елларга Алабуга муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасын раслау турында»гы 2016 елның 21 ноябрендәге 1473 нче санлы карарын гамәлдән чыгарырга.
3. Финанс-бюджет палатасына (Э. И. Садыйкова) җирле бюджет акчалары хисабына «2019-2023 елларга Алабуга муниципаль районында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларын үстерү» муниципаль программасы чараларын финанслауны күздә тотуны тәкъдим итәргә.
4. Әлеге карар массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми басылып чыгарга тиеш.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад һәм проектлар буенча урынбасары Р. Р. Закировка йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин